ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2020 елның 12 мартында
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 3, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 4 статьяның 1 өлешендәге 12 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«12) Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәмен күрсәтә торган медицина оешмалары исемлеген формалаштыру тәртибен билгеләү;»;

2) 5 статьяның 11 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«11) Татарстан Республикасы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәмен күрсәтә торган медицина оешмалары исемлеген раслау;»;

3) 28 статьяның 2 өлешендәге 3 пунктында «медицина ярдәме стандартларын» сүзләрен «медицина хезмәткәрләре күрсәтә торган медицина ярдәменең медицина ярдәме сыйфатын бәяләү критерийларына туры килүен» сүзләренә алмаштырырга;

4) 32 статьяның 4 өлешен үз көчен югалткан дип танырга.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, бу Законның 1 статьясындагы 3 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 3 пункты 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2020 ел, 28 март
№ 15-ТРЗ